КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 3 май г.Казань № 411

Эпидемия күрсәткечләре буенча профилактик прививкалар ясау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акча күләмен исәпләү методикасын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Эпидемия күрсәткечләре буенча профилактик прививкалар ясау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акча күләмен исәпләү методикасын расларга.

2. Эпидемия күрсәткечләре буенча профилактик прививкалар ясау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчаның исәп-хисап күләменә ел саен, Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча баш дәүләт санитария табибы карары нигезендә Татарстан Республикасында фаразлана торган эпидемиологик вазгыятьне исәпкә алып, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында эпидемия күрсәткечләре буенча профилактик прививкалар ясау өчен вакциналарны үзәктән сатып алуга каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә төзәтмәләр кертелергә тиеш дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин